Расланды

Субаш төп гомуми белем мәктәбе директоры

_______________ Р.М. Галиева

Татарстан республикасы
Балтач муниципаль районы
Субаш төп гомуми белем мәктәбенең
2015-2016 нчы уку елына
укыту-тәрбия эше планы

План 2015 нче елның 15 август
педсовет утырышында кабул ителде.
Беркетмә № 1. 15 август 2015 ел.
Мәктәпнең № 61, 29.08.15 приказы
нигезендә планны гамәлгә ашырырга

# Эчтәлек.

**I 2014-2015 нче уку елында укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ...........2 бит.**
1. Укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ........……............................................. ....2 бит.
2. Методик эшчәнлеккә анализ...........…………............................................ 5 бит.
3. Эчке контрольгә анализ..........…………….............................................. .....10 бит.
4.Тәрбия эшчәнлегенә анализ........…………….................................................. 11бит.
5. Психологик эшчәнлеккә анализ...........………................................................15 бит.
6. Материаль-техник базаны ныгыту буенча анализ……………………......... 19бит
7. Мәктәп китапханәсе эшчәнлегенә анализ...........…......................................... 21бит.
8. Башлангыч методик берләшмәләрнең эшчәнлегенә анализ............................ 24бит
9. Гуманитар фәннәр методик берләшмәсенең эшчәнлегенә анализ.................. 28 бит
10. Физкультура-технология методик берләшмәләрнең эшчәнлегенә анализ. ...30 бит
11. Төгәл фәннәр методик берләшмәләрнең эшчәнлегенә анализ....................... 32 бит
**II. 2015-2016 нчы уку елына укыту-тәрбия бурычлары................ .......34 бит.**
**III. 2015-2016 нчы уку елына укыту-тәрбия планы...................................35 бит.**
1. Педагогик кадрлар белән эш, аларның квалификациясен күтәрү, аттестация планы ...................................................................................................................... 35 бит.
2. Укыту-тәрбия эшчәнлеген оештыру................................................................. 39 бит.
3. Тәрбия чаралары................................................................................................. 42бит.
4. Эчке контроль...................................................................................................... 45 бит.
**IV. Кушымта**
-мәктәп китапханәсенең эш планы........................................................................57 бит
-методик берләшмәләрнең эш планы................................................................... 68 бит
- дәүләт йомгаклау аттестациясе имтиханнарына анализ.................................. 81 бит
-сәләтле укучылар белән эшкә анализ.................................................................. 82 бит
- еллык контроль эшләр графигы………………...…………………………… 83 бит

**2014-2015 нче уку елында укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ.**

Узган уку елында педколлектив эшчәнлекне еллык укыту-тәрбия планы нигезендә, түбәндәге бурычларны тормышка ашыру буенча оештырды**:**

1. Сәләтле укучыларны үстерү, барлау максатыннан эшчәнлекне төрле формаларда оештыру.( олимпиадаларда катнашу, фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләү)
2. Дәрестән соң эшчәнлекнең эффектлылыгын арттыру.(түгәрәкләрнең нәтиҗәле эшләвен таләп итү)
3. Укучы шәхесен һәрьяклап үстерерлек итеп, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә ярдәм итәрлек сингапур системасын кулланырга өйрәнү.

«Мәгариф турында» ТР законының балаларның белем алуга хокукын тәэмин итү турындагы статьясында күрсәтелгән бурычлар үтәлде. Ел дәвамында укуын ташлаучы, икенче елга классында кабат калучы укучылар булмады. Узган уку елын 90 укучы белән башлап, 90 укучы белән тәмамладык.

Башлангычның 4 классында 28 , урта звеноның 5 классында 62 укучы уку елын тәмамлады.

Ел дәвамында сәламәтлеге чикләнгән 2 укучы өйдә укытылды ( 5кл.-Нәбиев Фәндүс, 9 класс- Фазылҗанова Фидалия).

9 классны 20 укучы тәмамлады. Шуларның 10- ы төрле уку йортларына укырга керде. (Арча педколледжы, Авиатөзелеш колледжы, Үрнәк профлицеена, Элемтә колледжы, индустриаль-педагогика техникумы, медколледж). Калган 8 укучы 10 сыйныфны Урта Көшкәт, 1 укучы Куныр мәктәбендә дәвам итәчәк. 1 инвалид укучы авылда эшкә урнашты.

2011-2012 нче уку елыннан районның барлык 1 сыйныфлары яңа федераль дәүләт белем стандартлары буенча укый башлады. Узган уку елында дәвам итте. Барлыгы безнең мәктәптә 28 укучы яңа стандартлар буенча белем алды. Мәктәп “Перспектив башлангыч мәктәп” укыту-методик комплекты белән эшләде. Шулай ук дәресләрдә сәламәтлекне саклау технологияләре, интерактив методлар, яңа информацион технологияләр, уен технологияләре, өлешчә-эзләнү методикасы укытучылар тарафыннан киң кулланыла.

Шахмат, инглиз теле, хореография, хәрәкәтле уеннар юнәлешендә дәрестән тыш эшчәнлек оештырылды.

Яңа ФДС буенча мәктәптә эшче төркемнәр һәм мәктәпнең төп белем программасына нигезләнеп, норматив документлар, локаль актлар, приказлар язылды, укыту планнары, дәреслекләр сайланылды, укытучылар тарафыннан эшче программалар төзелде, ата-аналар белән килешүләр эшләнелде. Район психологлары белән очрашулар узды. Бу имтиханнар вакыты алдыннан зур ярдәм булды.

Узган уку елында 1 нче класс укучылары 5 көнлек, калган барлык класслар да 6 көнлек эш режимында эшләде. Укучылар 19 уку кабинеты, 1 спорт залы, көрәш бүлмәсендә шөгыльләнде. Башлангыч класс укучылары өчен 1 озайтылган көн төркеме оештырылды.

Үзебезнең җирлектә яшәгән барлык балалар да укуга тартылды һәм аларның дәрескә йөреше һәркөн системалы рәвештә контрольгә алынды, нәтиҗәләр ясалды.

| Класс | Укучы саны | Калдырган дәрес | | Уртача күрсәткеч | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | көн | дәрес | көн | дәрес |
| 1-4 | 28 | 16 | 34 | 5,7 | 11 |
| 5-9 | 62 | 36 | 58 | 1,7 | 21 |
| 1-9 | 90 | 52 | 92 | 7,4 | 32 |

Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, 1 укучы уртача 8,4 көн яки 25 дәрес калдырган. Иң зур күрсәткеч (10,7 көн, 64 дәрес (узган ел - 11 көн, 53 дәрес урта звено) югары звенога туры килә. Бу укчыларның справка нигезендә авырып калган дәресләре.

Мәктәпнең укыту планы Татарстан Мәгариф һәм Фән министрлыгы раслаган (приказ №4154/12, 09.07.2012, №7699/12, 23.06.2012 ел) Региональ базис укыту планы нигезендә төзелде. Программа материалы барлык фәннәрдән дә үтелеп бетте. Укучыларга һәр фәннең үз стандартыннан чыгып белем бирелде.
Узган уку елы нәтиҗәләре буенча мәктәптә белем сыйфаты 44%. Еллык билгеләр буенча «5» кә генә тәмамлаучы 3 укучы (3,3%), «4-5» кә 35укучы (39%), калганы «3»кә, "4"һәм "3" генә уку елын тәмамлады.

| Уку елы | Укучы саны | Белем сыйфаты | «5» | «4-5» | Өлгереш |
|---|---|---|---|---|---|
| 2011-2012 | 132 | 48,3% | 3 (2,5%) | 54 (45,8%) | 100% |
| 2012-2013 | 128 | 52% | 4 (3,3%) | 59 (48%) | 100% |
| 2013-2014 | 104 | 44% | 5(5,1%) | 38 (38,7%) | 100% |
| 2014-2015 | 90 | 44% | 3(3,3%) | 35(39%) | 100% |




Саннардан күренгәнчә, «5»кә генә укучылар саны бу уку елында кими баруы күзәтелә. Укучылар саны кимүгә карамастан, «5» кә, "4» генә укучылар проценты арткан. Ләкин укучыларның белемгә тартылуы кимемәгән.

**Аерым фәннәр буенча белем сыйфаты түбәндәгечә булды (%):**

| № | Фәннәр | 2012-2013 | 2013-2014 | 2014-2015 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татар теле | 69,4 | 67 | 68 |
| 2 | Әдәбият | 81 | 77 | 80 |
| 3 | Рус теле | 56,2 | 51 | 43,5 |
| 4 | Литература | 76,67 | 73 | 72,5 |
| 5 | Инглиз теле | 72 | 73 | 64,5 |
| 6 | Математика | 67,7 | 62 | 66 |
| 7 | Физика | 74,6 | 77 | 78,5 |
| 8 | Химия | 76,6 | 70 | 84 |
| 9 | Биология | 76.9 | 72 | 81 |
| 10 | Информатика | 88,7 | 98 | 89 |
| 11 | География | 84,62 | 78 | 81 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Тарих | 90 | 86 | 85 |
| 13 | Җәмгыять белеме | 91 | 88 | 90 |
| 14 | Физкультура | 98,3 | 98 | 97 |
| 15 | ТИН | 97,37 | 95 | 100 |
| 16 | Табигать белеме | 83,3 | 70 | 90 |
| 17 | Технология (м) | 98,5 | 98 | 98 |
| 18 | Технология(к) | 98,5 | 98 | 98 |
| 19 | Музыка | 97,67 | 98 | 97 |
| 20 | Сынлы сәнгать | 86 | 94 | 90 |
| 21 | Искусство (Музыка и ИЗО) | 94 | 94 | 87 |

Аерым фәннәрне караганда, рус теле, инглиз теле фәненнән белем сыйфатының кимүе күзәтелә. Укытучылар Хабибуллина В.А, Нурмухаметова Ф.Н ларга алдагы уку елында белем сыйфатына игътибар итәргә. Химия, биология фәннәреннән белем сыйфаты үсә баруы күренә. Ләкин бу фәннән нәтиҗәлелек түбән, чөнки фәнне соңгы елда яшь укыучы укыту сәбәпле, тәжрибә җитеп бетмәвен күрдек. Укытучы Сабирова Г.Р га алдагы уку елында укучыларның белемен объектив билгеләү алымнарын өйрәтергә.

Һәр класста укучыларның белем дәрәҗәсенә күз салсак, нәтиҗәләр түбәндәгечә:

Бер “3” ле белән калучылар узган елгыдан арткан. Моңа да игътибарлы булып, белем сыйфатына бәйле булуын истән чыгармаска.

| Класс | Уку елы ахырында укучы саны | «5»кә генә | Бер генә «4»ле | «4-5»кә | Бер генә «3» ле | «3-4»кә | «3»кә генә | Белем сыйфаты (%) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 6 | - | - | 3 | - | 3 | 3 | 50 |
| 3 | 7 | - | - | 4 | 1 | 3 | 3 | 57 |
| 4 | 11 | - | - | 7 | - | 4 | 4 | 64 |
| 5 | 10 | 1 | - | 4 | 1 | 5 | 5 | 50 |
| 6 | 10 | 1 | 1 | 3 | 1 | 6 | 6 | 40 |
| 7 | 11 | - | - | 3 | - | 8 | 8 | 27 |
| 8 | 11 | 1 | - | 5 | - | 5 | 5 | 54,5 |
| 9 | 20 | - | - | 6 | 6 | 14 | 14 | 30 |
| Барлыгы | 86 | 3 | 1 | 35 | 9 | 48 | 48 | 44 |

**Дәүләт йомгаклау аттестациясена анализ.**

9 нчы классны тәмамлаучылар да дәүләт йомгаклау аттестациясен төп дәүләт имтиханы (ОГЭ) формасында үтте. Ул 28 майдан 17 июньгә кадәр дәвам итте. Рус теле һәм математикадан, икенче тапкыр татар теленнән бердәм республика тесты тапшырдылар. Сайлап алу фәннәреннән имтихан эшләре республика имтихан коллегиясе тарафыннан үткәрелде һәм тикшерелде.1 укучы (Фазулзянова Ф.Ф) ГВЭ тапшырды. Нәтиҗәләр түбәндәгечә булды:

| Фән | Барлык укучы | «5» | «4» | «3» | «2» | Белем сыйфаты (%) | Өлгереш (%) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Математика | 19 | 2 | 10 | 7 | - | 63 | 100 |
| Рус теле | 19 | 1 | 5 | 13 | - | 31,5 | 100 |
| Татар теле | 19 | 2 | 17 | - | - | 100 | 100 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Информатика | 3 | 1 | 1 | 1 | - | 67 | 100 |

Әгәр саннарга игътибар белән күз салсак, монда нәтиҗәләр яхшы. Укучылар сайлау имтиханнарында ел саен бер үк фәннәргә өстенлек бирәләр иде. (биология) Быел информатика фәнен сайлаучылар булды. Математика, рус теле, татар теле, информатика фәннәреннән (укытучылары Гарифуллина Р.Р, Хабибуллина В.А, Габитова С.И, Хуснетдинов А.А) укучыларны имтиханга әзерләүгә бик җаваплы карады. Безнең укучылар яңа формада үткәрелгән рус теле, татар теле, информатика имтиханында икеле алмадылар. Ләкин математика фәненнән төп этапта 1 укучы икеле алып, кабат төзәтә алды. Шул сәбәпле барлык укучылар да гадәти аттестат алуга иреште. Киләчәктә укучыларның белемнәрен бәяләү бары тик ТДИ (ОГЭ) формасында гына булачак. Узган уку елларында математика, рус теле фәненнән 100% сыйфат булса, быел андый сыйфатка ирешеп булмады.

Быелгы имтиханнардан **нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: төп дәүләт имтиханын укучының уңышлы тапшыруына ирешү өчен, фән укытучысы, класс җитәкчесе, эти-әниләрнең бердәм эшчәнлеген түбән сыйныфлардан ук төшендерергә кирәк.**

2014-2015 нче уку елында **мәктәптә методик эшчәнлек** алга куелган бурычларны үтәү һәм аларны мәгариф программалары, укыту-тәрбия процессы аша тормышка ашыруга юнәлтелде. Коллектив үзенең эшчәнлеген “Укытуда яңа информацион технологияләр кулланып, укучыларның белем сыйфатын күтәрү” методик темасы буенча дәвам итте. ФДББС ы укытуына күчү шартларына тәңгәл рәвештә әлеге тема буенча эш беренче ел алып барылды. Мәктәп укытучылары Сингапур системасы буенча беренче этапны укуга ирештеләр. **Соңгы 2 елда укучыларны иҗади конкурсларга** тарту кимегән иде, катнаштыру интернет конкурсларга гына кайтып калды. Бу уку елында укытучылар, укучылар актив булды.. “Ел укытучысы” конкурсында яшь биология укытучысы Сабирова Г.Р, “Ел сыйныф җитәкчесе” конкурсынды татар теле укытучысы Васильева Г.Ф катнашып, муниципаль этапта номинацияләрдә, “Өстәмә белем бирү педагогы” конкурсында Хөснетдинов А.А катнашып җиңүче булдылар.Укытучылар спартакиадасында 3 укытучыбыз (Николаев И.И, Петрова Г.Н, Сабирова Г.Р) район данын яклап, республика этабында катнашты. Яхин укулары республика конференциясендә 3 укытучы (Антонова Н.Г, Габитова С.И, Васильева Г.Ф) 3дәрәҗә Диплом, татар теле мастер-класс бәйгесендә Габитова С.И эссе номинациясендә, методик копилка конкурсында Антонова Н.Г шулай ук номинациядә муниципаль этапта җиңүче булдылар.

2014-2015 нче уку елында мәктәптә методик хезмәт алдына «укыту-тәрбия процессының эчтәлеген, структурасын үзгәртү шарты буларак, укытучыларның һөнәри осталыгын өзлексез камилләштерү» максаты куелды. Бу максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1. Укытуның сыйфатын күтәрү буенча эшчәнлекне дәвам итәргә.
2. Укыту процессына яңа укыту технологияләрен кертергә.
3. Мәктәпнең информацион базасын киңәйтү, яңарту.
4. Укучыларны фәнни-тикшеренү, проект эшчәнлегенә тартырга һәм фәнни-практик конференцияләрдә, конкурсларда актив катнашырга.
5. Белем алырга сәләтле укучылар белән эшчәнлекне арттырырга, аларның фән олимпиадаларында, интеллектуаль марафоннарда катнашуын тәэмин итәргә.
6. Педагогик совет эшчәнлегенең яңа форма һәм методларын эзләргә.
7. Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча эшне дәвам итәргә.

Куелган бурыч һәм максатлардан чыгып, методик эшчәнлек түбәндәге юнәлешләрдә оештырылды:

- мәктәптә методик эшчәнлекнең иң югары формасы буларак, педагогик совет утырышлары;
- методик совет эшчәнлеге;
- укытучыларның квалификациясен һәм осталыгын күтәрү;
- иҗади эшләүче методик берләшмәләр эшчәнлеге;

- индивидуаль-методик һәм инновацион эшчәнлек – алдынгы тәҗрибә уртаклашу;
- аналитик-диагностик эшчәнлек,
- кабинетларның методик җаһазланышын яңарту.

Узган уку елында, планда каралганча, 3 тематик педагогик совет утырышы түбәндәге темалар буенча уздырылды:

- Эш нәтиҗәләрен анализлау, 2014-2015 нче уку елына мәктәпнең эш планын кабул итү, бурычлар билгеләү.
- Эшчәнлек методында дәрес типлары;
- Тәрбия өлкәсендә инновацион технологияләр;
- Имтиханнарга әзерлек. Диагностик тестларга анализ;
- Дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә УУГ күрсәтү;
- 1,5, сыйныфларда адаптация чоры.
- 4 нче сыйныф укучылары мониторингына анализ;

-Укучыларны класстан класска күчерү.
- Чыгарылыш класс укучыларын имтиханнарга кертү.
- Чыгарылыш класс укучыларына аттестатлар тапшыру.

Педсоветларның барысы да алдан әзерлек белән, куелган бурычлардан чыгып үткәрелде. Түбәндәге темаларга эшлекле чыгышлар тыңланды: (Габитова С.И - “Эшчәнлек методында дәрес типлары”, Петрова Г.Н “Тәрбия өлкәсендә инновацион технологияләр”, Антонова Н.Г, Гильфанова Н.Ф, Алексеева Н.З, Фролова Р.В, Васильева Г.Ф, Нурмухаметова Ф.Н, Закиров Ф.М “Дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә УУГ күрсәтү”) . Педсоветларда чирек, яртыеллык нәтиҗәләре, педагогик коллектив эшчәнлеге, ДЙА әзерлек, укучылардан алынган анкеталар анализланды, алга куелган бурычларны үтәү юллары эзләнде. Фикер алышулар бик җанлы үтте. Алдагы уку елында сайт шәхси кабинетлардагы факультатив, сообществолардан иркен файдаланырга, аралашырга.

9 кешелек составтан торган методик совет белән укыту эшләре буенча директор урынбасары җитәкчелек итте. Методик совет утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:

- 2013-2014 нче уку елында методик эшчәнлеккә анализ, яңа уку елына эш планлаштыру.
-тематик педсоветларга әзерлек
- 1,5, класс укучыларының адаптация чорын өйрәнү.
- ФГОС таләпләре буенча башлангыч укытучыларының эш программаларын карау.
- олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү.
- Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлекне методик яктан оештыру,информацион эшчәнлек.
- 3-4 нче сыйныф укучыларының яңа белем стандартлары буенча белем алуның нәтиҗәлелеге;
- Сынау шарты белән үткәрелгән имтихан нәтиҗәләре.
-курсларда булган укытучыларның отчеты
- олимпиадаларның район турлары нәтиҗәләре.
-эчке контроль планы буенча контроль эшләр үткәрү, аларны анализлау.
- фән атналыкларына әзерлек.
- укытучыларны аттестациягә әзерләү.
- мәгариф һәм фән министрлыгының № 21534/14 14.11. 14 “О направлении методических рекомендаций по введению курса “Черчение”
- имтиханнарга әзерлек
- 2014-15 нче уку елы йомгаклары, яңа уку елына әзерлек.
-2015-2016 нче уку елына план төзү.

Укытучылар тарафыннан, тәҗрибә уртаклашу максатында, мәктәп күләмендә ачык дәресләр, дәрестән тыш чаралар күрсәтелде. Озайтылган көн төркеме буенча район семинары уңышлы үтте. Тәрбияче Саттарова Р.Ф үз эшчәнлеге белән уртаклашты Мәктәпнең үзендә туризм семинары, Тукай көннәре, Туган тел атналыгы, төгәл фәннәр атналыгы зур хәзерлек белән үтте Ләкин ачык чаралар күрсәтү, үзара дәресләргә керү

җитәрлек дәрәҗәдә булмады. Ачык дәрес, чаралар методик берләшмә анализланды. Киләчәктә укытучылар үзләре теләп тәҗрибәләре белән уртаклашса иде.

2014-2015 нче уку елында **методик совет** каршында 5 методик берләшмә үз юнәлешләре буенча эшчәнлек оештырды. Һәр берләшмә үз алдына укытучыларның һөнәри осталыгын үстерү; укучыларның кызыксынулары, сәләтләре һәм мөмкинлекләрен ачыклап, төрле интеллектуаль конкурсларда катнаштыру; укытучыларны һәм укучыларны проект һәм тикшерү эшчәнлегенә киңрәк тартуны төп бурыч итеп куйды.

Һәр методик берләшмә үз эшен план нигезендә алып барды. Берләшмә утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:

1. Узган уку елына анализ, яңа уку елына эш планын, укытучыларның календар-тематик планнарын раслау.
2. Фән атналыкларын планлаштыру.
3. Сәләтле укучылар белән эш оештыру. Олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү, район, республика турларында катнашу.
4. Фәнни-тикшеренү, проект эшләре белән төрле конкурсларда катнашу.
5. Укучыларның фәнни-гамәли конференциясен үткәрү.
6. Имтиханнарга әзерлек.
7. Башлангыч мәктәп бүген, иртәгә.
8. Укучыларның җәйге ялын оештыру

Һәр берләшмә үз эшчәнлеген аерым методик тема буенча оештырды.

| МБ | Тема |
|---|---|
| Рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле , татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучылары МБ | Укучы шәхесен һәрьяклап тәрбияләү һәм төпле белем бирүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдә заманча информацион технологияләр куллану. |
| Математика, физика, информатика, химия, биология, география укытучылары МБ | Укучыларның иҗади эшчәнлекләрен оештыру аркылы шәхси мөмкинлекләрен киңәйтү һәм үстерү. |
| Музыка, рәсем сәнгате, технология, физкультура, ОБЖ укытучылары МБ | Фәннәрне укытуда иннавацион технологиялщр кулланып, шәхесне социаль үстерү. |
| Башлангыч класс укытучылары һәм тәрбиячеләре МБ | Яңа стандартларга күчкәндә укучыларның танып белү активлыгын үстерү. |
| Класс җитәкчеләренең МБ | Сыйныф җитәкчеләренең осталыгын күтәрү аша мәктәптә тәрбия бирү формаларын һәм методларын тормышка ашыру. |

**Узган** уку елында октябрьдә мәктәптә фән олимпиадаларының сайлап алу турлары үткәрелде, нәтиҗәләр чыгарылды. I турда җиңүчеләр олимпиадаларның район турларында катнаштылар. 8 нче сыйныф укучылары Вафин Илсур ТИН фәненнән район призеры, Хабибуллина Азалия рус теле фәненнән җиңүче булды. Таблицада призлы урыннар:

| Уку елы | Призлы урын |
|---|---|
| 2010-2011 | 5 |
| 2011-2012 | 7 |
| 2012-2013 | 6 |
| 2013-2014 | 2 |

| 2014-2015 | 2 |
|---|---|




**Аерым фәннәр буенча ныклы белемнәрен күрсәткән укучылар:**
**2013 ел**

| Укучының фамилиясе, исеме | Класс | Фән | Призлы урын |
|---|---|---|---|
| Хакимзянов Ранил | 11 | Технология | призер |
| Николаев Артем | 8 | ОБЖ | Призер |
| Степанова Регина | 9 | Биология | Призер |
| Хабибуллина Алина | 11 | Русский язык<br>Литература | Җиңүче<br>Җиңүче |
| Васильев Ильяр | 11 | Право | призер |
| **2014 ел** | | | |
| Габитова Ландыш | 9 | Русский язык<br>Татарский язык | Призер<br>призер |
| **2015 ел** | | | |
| Вафин Илсур | 8 | ТИН | призер |
| Хабибуллина Азалия | 8 | Русский язык | Җиңүче |
| Нурмухаметова Әдилә (халыкара олимпиада) | 8 | Татар теле,әдәбият | призер |

Укучылар күбрәк үз көчләре белән әзерлекле. Быел да призерларның аз булуы күңелне борчый. Шулай да татар теле һәм әдәбияты фәненнән халыкара олимпиадада 3 нче призлы урын алу мәктәпнең рейтингын күтәрә алды. Бу районның рейтингысына да йогынты ясады. Чөнки мәгариф министрлыгы ясаган анализда аерым билгеләп үтелде. Шулай да укучыларны ныклап аерым әзерләү җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Моны түбән класслардан ныклап әзерләү кирәк. **Укучыларыбызның нинди фәннәр буенча системалы рәвештә уңышка ирешүләрен карасак, еллык нәтиҗәләр түбәндәгечә:**

| Фән исеме | 2009-2010 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2013-2014 | 2014-2015 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Рус теле | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Рус әдәбияты | - | | 1 | 1 | | |
| Татар теле | - | 1 | 1 | - | 1 | 1 |
| Татар әдәбияты | - | - | - | - | | |
| Инглиз теле | - | - | - | - | | |
| Тарих | - | - | - | - | | |
| Җәмгыять белеме | - | - | - | - | | |
| Экономика | - | - | - | - | | |
| Хокук | - | - | 1 | 1 | | |
| МХК | - | - | - | - | | |
| Эшмәкәрлек нигезләре | - | - | - | - | | |
| Математика | 1 | - | 1 | - | | |
| Информатика | - | 1 | - | - | | |
| Физика | - | - | - | - | | |
| Политехнология | - | - | - | - | | |
| Астрономия | - | - | - | - | | |
| Химия | - | - | - | - | | |
| Биология | - | 1 | 1 | 1 | | |
| География | - | - | - | - | | |
| Геология | - | - | - | - | | |
| Экология | - | - | - | - | | |
| Технология | 1 | 1 | 1 | 1 | | |
| Физкультура | - | - | - | - | | |
| ОБЖ | | 1 | - | 1 | | 1 |

Саннардан күренгәнчә, биология, татар теле, рус теле, ТИН кебек фәннәр тотрыклы позициядә торалар.. Сәләтле укучылар белән иртәгә олимпиада буласы көнне генә шөгыльләнеп, уңышка ирешеп булмаячагы көн кебек ачык. Физкультура, химия, тарих, җәмгыять белеме, инглиз теле, география, физика, фәннәреннән соңгы елларда урыннар бөтенләй юк. Бу фән укытучыларына уйланырлык урын бар. Алдагы уку елында әзерлекне арттырырга.

**Башлангыч сыйныфлар** буенча да олимпиадалар үткәрелеп килә. Ләкин әле укучыларны ныклап әзерләү шулай ук җитеп бетми.

**Тәкъдим:** Башлангыч сыйныф укытучыларына сәләтле укучылар белән эшне тагын да арттырырга, бигрәк тә рус теле, инглиз теленнән әзерлекне көчәйтергә. Бу уку елында рус теле фәненнән соңгы урыннарда булу әзерлекнең бөтенләй булмавын күрсәтә. Алдагы уку елында олимпиадага әзерлек барышын контрольгә алырга.

| Укучының фамилиясе, исеме | Класс | Фән | урыны | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2013-2014 | 2014-2015 |
| Хабибуллина Азалия | 4 | Русский язык | 23 | | | | |
| Саттаров Дамир | | | | 7 | | | |
| Николаева Индира | | | | | 20 | | |
| Степанова Рамиля | | | | | | 31(14,5 б.) | |
| Муллагалиева Нәргизә | | | | | | | 39(20б) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Нурмухаметова Әдилә<br>Ильин Фәнзил<br>Степанова Рамиля<br>Муллагалиева Нәргизә | 4 | Инглиз теле | 12 | 20 | - | 25(22б.) | 14(22б) |
| *Нурмухаметова Әдилә*<br><br>*Гильманов Фәнзил*<br>*Николаева Индира*<br>*Степанова Рамиля*<br>*Николаев Вильдан* | *4* | *Математика* | *14* | *7* | *16* | *6 (6б.)* | *6(30б)* |

Узган уку елында **эчке контроль** план нигезендә түбәндәге юнәлешләрдә алып барылды:
- педагогик кадрлар эшчәнлеге;
- укучыларның белем һәм күнекмәләре торышы;
- мәктәп документациясе белән эшчәнлекнең торышы;
- һәр балага белем алуга мөмкинлекләр булдыруның үтәлеше;
- фәннәрне укытуның торышы;
- имтиханнарга әзерлек эшчәнлеге.
- адаптация чорын өйрәнү
-электрон журнал белән эш

Узган уку елы уртасында педагоглар белән «Яңа белем стандартлары, укыту программалары, методик ярдәмлекләр» турында методик киңәшмә узды. Методик берләшмә утырышларында һәр фән укытучысының календарь-тематик планнары карап расланды. Методик совет тарафыннан олимпиада, конкурс, фән атналыклары, консультацияләр графиклары төзеп расланды. Укытучылар һәм укучылар әлеге чараларда ел дәвамында актив катнаштылар, дипломнар һәм грамоталар белән бүләкләнделәр.

Мәктәпнең методик берләшмәләре укучыларны йомгаклау аттестациясенә әзерләү буенча актив эш алып бардылар. Сынау имтиханнары өчен материаллар әзерләнде.

Коллективның һәр педагогы **үз белемен күтәрү**, елдан-ел камилләштерү өстендә системалы эш алып барырга тиеш. Бу юнәлештә дә укытучыларның эшчәнлеге планлы рәвештә алып барыла. Һәр укытучы үз белемен күтәрү планы буенча максатчан эшли, белем күтәрү курсларында була. Узган уку елында барысы 4 укытучы, 2 укытучы югары, 2 укытучы беренче категориягә, 4 укытучы СЗДга аттестацияләнде. Аттестация узу электрон вариантта үткәрелде. Гарифуллин Р.Г, Закиров Ф.М, Васильева Г.В үз белемен күтәрде. Уку елы дәвамында аттестациягә керүче укытучылар белән эш оештырылды, аларның эшчәнлеге тикшерелде һәм анализланды. Укытучылар аттестацион курсларда тиешле вакытларында белем алдылар.

Фәннәрне укытуның торышын өйрәнгәндә, методик берләшмәләр һәм администрация тарафыннан дәресне оештыруның форма һәм методларын камилләштерү һәм дифференциальләштерүгә аерым игътибар бирелде.

1,4,5,9, классларда гомуми-класс контроле үткәрелде.

6,7,8 классларда яңа өйрәнә башлаган фәннәрне укытуның торышы тикшерелде. Укытучыларга дәреснең форма һәм методларын камилләштерү; укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру; дәрескә куелган максатларның үтәлеше; предметара бәйләнеш; дәресләрнең фәннилеге, аңлаешлылыгы, тормыш белән бәйләнеше, системалылыгы һәм эзлеклелеге; дәресне оештыру һәм үткәрү буенча методик, практик һәм психологик ярдәм күрсәтелде.

Каралган һәм анализланган дәресләр буенча нәтиҗә:
- укытучылар укыту материалларын яхшы беләләр;
- дәресләрдә алдынгы технологияләр, компьютер технологияләре кулланалар (Гильфанова Н.Ф, Гарифуллин Р.Г, Закиров Ф.М, Антонова Н.Г, Хөснетдинов А.А );

- укытучылар дәресләрдә, өйгә эшләр биргәндә төрле дәрәҗәдә үзләштерүче укучыларның мөмкинлекләрен исәпкә алып эшлиләр;
- укытучылар укучыларның шәхси сыйфатларын үстерүне (фикерләү, сөйләм, ихтыяр көче, әхлаклелек, аралашу культурасы) максат итеп куялар, тормышка ашыралар.
Укучылар дәрестә актив, оешкан; белем дәрәҗәләре уртача. Һәр класста фәннәрне үзләштерү дәрәҗәсе түбән булган 1әр укучы бар.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү өчен төп предметлардан ел дәвамында административ контроль эшләр алынды. Контроль эш нәтиҗәләрен анализлаганда, чирек билгеләренең административ контроль эш нәтиҗәләреннән югары булуы күзәтелә. График нигезендә мониторинглар үтте һәм анализланды.

Уку елы дәвамында укытучыларның мәктәп документациясе (класс журналлары, шәхси делолар) белән эшчәнлеге контрольга алынды. Укучыларның контроль, язма, лаборатор эш дәфтәрләре тикшерелде. Электрон журнал белән эш алып барылды. Электрон класс журналлары белән эшчәнлекне тиешле таләпләргә туры китереп башкарган укытучылар: Закиров Ф.М., Галиева Р.М, Гарифуллин Р.Г, Гильфанова Н.Ф, Габитова С.И лар булды.

Авылда булган һәр баланы мәктәптә укыту, аларга белем алу өчен шартлар тудыру да ел дәвамында контрольдә булды. План нигезендә укучыларның дәрескә йөреше, авыр үзләштерүчеләр белән эшчәнлекнең торышы, авыру балаларны өйдә укытуның торышы, ФДББС керү сәбәпле 1-4 нче сыйныфларны өйрәнү, өйгә эшләр бирүнең күләме тикшерелде һәм директор алды, завуч алды киңәшмәләрендә анализланды.

Имтиханнарга әзерлекнең торышы даими рәвештә контрольдә торды. Ай саен сынау имтиханнары уздырылып, анализланды. Кабинетларда имтиханнарга әзерлек буенча стендлар вакытында ясалды, консультацияләр үткәрелде.

**Нәтиҗәләр:**

1.МБ утырышларының тематикасы МБ алдында торучы төп проблемалы сорауларны чагылдыра.

2. Сайлап алынган чаралар комплексы фәнни-методик бурычлар системасын минималь күләмдә чишәргә ярдәм итә.

3 Контрольнең төп юнәлешләре һәм дәресләргә йөрү тематикасы дөрес сайланган. Бу укыту сыйфатын, дәрес структурасын, дәрестә кулланыла торган метод һәм формаларны сайлап алуны яхшыртуга ярдәм итә.

4. Хаталарны төзәтү һәм коррекцияләү буенча тәкъдимнәр методик совет, методик берләшмә утырышларында, директор алды киңәшмәләрендә бирелә.

**Тәкъдимнәр:**

1.Төп мәктәптә ФДББСына күчү шартларында алдынгы тәҗрибәне үзләштерү, гомумиләштерү һәм үз эшчәнлегеңә кертү өстендә эш алып барырга.

2. МБ рамкаларында семинар – практикумнарны сингапур системасын өйрәнү итеп үткәрүне дәвам итәргә.

3. Укытучыларны профессиональ конкурсларда күбрәк катнаштырырга.

# МБГУ “Субаш төп гомуми белем мәктәбе”нең 2014-2015 нче уку елына тәрбия эшенә анализ

2014-2015 нче уку елында мәктәптә укыту процессы белән беррәттән , дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда әхлак, экологик рухи һәм физик тәрбияне үстерү, сәләтле балалар белән эш алымнарын камилләштерү проблемасын тормышка ашыруга юнәлдерелгән күпкырлы тәрбияви эшчәнлек алып барылды.

Бу уку елында педагогик коллектив алдына түбәндәге бурычлар куелган иде:

1. Педагогик технологияләрне тәрбия процессына кертү ярдәмендә укучыларның танып белү активлыгын үстерергә һәм интеллектуаль үсешенә ирешергә.

2.Укучылар үзидарәсен үстерү ярдәмендә укучыларның мөстәкыйльлеген, җаваплылыгын арттыруга ирешергә.

3.Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү, үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудырырга.

4.Әти-әниләр белән тыгыз элемтә булдырырга, педагогиканың мөһим проблемалары буенча укулар оештырырга

Алга куелган бурыч – максатларны тормышка ашыру өчен мәктәп колективы даими эш алып барды. Тәрбия эшчәнлеген оештыруда 9 класс җитәкчесе, 1 озайтылган көн төркеме тәрбиячесе катнашты. Алар укыту процессын сыйныфтан һәм мәктәптән тыш чаралар белән бәйләп алып бару өчен, һәр баланың үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларда укуга булган карашларын уңай якка үзгәртергә тырышып, кызыксындыру тудырып, халкына карата лаеклы варис булу, эшлекле, сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү өчен план нигезендә эшләде.

Тәрбия эше түбәндәге юнәлешләргә таянып алып барылды:

Танып белү
Патриотик һәм гражданлылык
Хокукый
Спорт-сәламәтләндерү
Хезмәт
Әхлак
Эстетик
Экологик

Танып белү юнәлешендәге тәрбия эшен тормышка ашыру максатыннан мәктәптә фән атналыклары, компьютер, интерактив такталар ярдәмендә тәрбияви дәресләр үткәрелде. 2 сентябрь көнне һәр сыйныф җитәкчесе ныклы әзерлек белән “Минем Кече Ватаным” дәресе үткәрде. Укучылар ел саен Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган “Русский медвежонок”, “ЧИП”, “Зирәк тиен”, “Көнгерә”, “КИТ” уен-конкурсларында, республика һәм район күләмендә үткәрелә торган ярышларда, фәнни-конференцияләрдә актив катнаштылар һәм матур күрсәткечләргә ирештеләр.

Укучыларга патриотик һәм гражданлык юнәлешендә тәрбия бирү максатыннан системалы рәвештә эш алып барылды. Мәктәбебездә хәтер көнен билгеләп үтү, үз халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары булган шәхесләрне искә төшерү, аларга багышлап тәрбия сәгатьләре үткәрү, Россия һәм Татарстан Конституциясе кабул итү көннәрен, Халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтү матур традициягә әйләнеп бара. Бу чаралар барысы да – патриотик аң, гражданлык позициясе тәрбияләүгә беренче адымнар. План нигезендә февральдә хәрби-патриотик айлык үткәрелде. Айлыкта барлык укучылар да актив катнашты. “Әтиләр бәйрәме”, традицион рәвештә мәктәп күләмендә “Аҗаган” хәрби-спорт уены, сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашулар тәрбияви һәм кызыклы булды. Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек сентябрь аенда ук башланды. Атна саен һәр сыйныф сәгатенен 10 минуты Бөек Җиңүгә багышланды. Сыйныф җитәкчеләре аерым план төзеп эшне оештвырдылар. Бөек Җиңүгә багышланган композицияләр ясалды, бу эшкә әти-әниләрнең ярдәме зур булды. 9 май-Җиңү көне зурлап билгеләп үтелде, ветераннарга котлау открыткалары җибәрелде, Субаш һәм Каенсар авыллары һәйкәлләре янында митинг үткәрелде. Бу уку елында да тарих укытучылары

тарафыннан мәктәптә “Гражданнарның хокуклары һәм бурычлары”, “РФ һәм РТ дәүләт символлары” темасы астында Парламент дәресләре үтте.

Мәктәптә хокук тәрбиясе тарих укытучысы, медсестра, ПДН, участок вәкиленең тыгыз элемтәсе аша алып барылды. Даими рәвештә әлеге темага багышланган тәрбия дәресләре (“Начар гадәтләрсез тормыш”), танып белү уеннары (“Тәмәкесез тормыш”, “Бала хокуклары”), “Тәмәкегә каршы акция” үткәрелде. Ноябрь ае мәктәптә хокук айлыгы дип игълан ителде. Айлык кысаларында сыйныф җитәкчеләре укучыларны хокуклары һәм бурычлары белән таныштырдылар, алар белән берлектә хокукый уеннар, викториналар, брейн-ринг үткәрелде. Шулай ук район полиция хезмәткәрләре вәкилләре белән дә очрашу бик кызыклы үтте, балалар үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар. Һәрбер класста ТР-ның 71нче законы буенча ныклы сөйләшүләр булды. Укучыларның сәламәтлеген, иминлеген кайгыртып, ТР-ның 71нче законы үтәлешен истә тотып мәктәп коллективы җаваплылыгында шимбә, каникул, бәйрәм көннәрендә мәдәният йортына рейдлар ясау ныклы системага салынды. Мәктәптә хокук бозуны профилактикалау отряды эшләде. Мәктәп буенча район күләмендә учетта торучы укучылар юк. Укучыларның иминлеген саклау - безнең төп бурыч. Даими участок инспекторы, балигъ булмаган балалар һәм яшьләр белән эшләү бүлеге белән даими элемтәдә торып, берлектә хокук бозуларны булдырмау буенча профилактик чаралар, әңгәмәләр үткәрелә,чыгышлар ясала. Район ГАИ хезмәткәрләре белән берлектә башлангыч сыйныф укучылары өчен юл йөрү кагыйдәләренә багышланган чара үтте. Укучылар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр, ә инде укытучылары рәхмәт хатлары алдылар. Уку елы барышында “Юл йөрү куркынычсызлыгы айлыгы”, “Балалар куркынычсызлыгы айлыгы”, “Экстремизмга – “Юк!” айлыклары үткәрелде.

Хокук бозуның бер төре булган коррупция тормышыбызда киң җәелеп килә. Укучылар да бу хакта хәбәрдар, аларга аңлату эшләре алып барыла. Шушы максаттан чыгып, мәктәпнең 2014 – 2015 нче уку елына коррупциягә каршы көрәш эш планы төзелде. Ата-аналар өчен стендка, мәктәп сайтына материаллар куелды, коррупциягә каршы көрәш атналыгы уздырылды. Атналык кысаларында плакатларга конкурс, укучылардан анкеталар алу, викторина, класс сәгатьләре, ачык дәресләр, әңгәмәләр, китап күргәзмәләре оештырылды. Күп кенә конкурсларда катнашып урыннар яуладылар. 4 нче сыйнф укучысы Фролова М.Р. аппликация ясап республикада җиңүче булды.

Укучыларны тәрбияләүдә спорт-сәламәтләндерү юнәлешенең аеруча роле зур. Төп максаты: яшь буында сәламәт яшәү рәвеше, спортка мәхәббәт тәрбияләү. Шушы максаттан мәктәптә күп төрле ярышлар, бәйгеләр, чаралар үткәрелде. Мәктәп спорт залында даими иртәнге гимнастика ясатылды. Ай саен “Сәламәтлек көне” билгеләп үтелде. Бу көнне ярышларда әти-әниләр дә катнашты. Укучылар бик теләп “Милләтләр кроссы”нда, “Татарстан чаңгы юллары – 2015” ярышында көч сынаштылар. Һәр класс җитәкчесе тәрбия сәгатьләрендә сәламәтлек, начар гадәтләргә, наркоманиягә каршы тәрбияви чаралар үткәрде

Мәктәптә балаларны спортка тарту буенча эш алып барыла. Кайбер спорт төрләре буенча сәләтле укучыларыбыз да шактый. Туризм, армспорт буенча күләмендә генә түгел, Россия күләмендә үткәрелгән спорт ярышларында да катнашып призлы урыннар яуладылар .

Укучыларның сәламәт яшәү рәвешен күздә тотып, мәктәптә “Путь к успеху” программасы буенча эш алып барылды. Әлеге программага караш укучылар, әти-әниләр тарафыннан да елдан-ел ныгый бара. Шул юнәлештә һәрбер класс үзенең планын булдырды, план нигезендә тәрбия дәресләрен үткәрү системага салынды.Уку елы башында һәм ахырында әти-әниләргә анкеталар үткәрелде, нәтиҗәләр билгеләнде.

Тәрбиянең хезмәт юнәлеше буенча традицон рәвештә үткәрелгән чаралар:

Өмәләр

Классларда уборкалар

Өлкәннәргә ярдәм операциясе

Мәктәп территориясен яшелләндерү

Чәчәкләр, гөлләр утырту

Мәктәп яны тәҗрибә участогында эшләү

Бөек Ватан сугышында һәлак булган ветераннарыбыз истәлегенә куелган һәйкәлне тәртиптә тоту.

Класстан тыш вакытта мәктәптә профориентация буенча ел саен системалы һәм планлы тәрбия эше алып барыла. Бу уку елы башында һөнәр сайлауга юнәлеш бирү планы төзелеп, шул план нигезендә эшләнде.Укучыларда авыл хуҗалыгына караган һөнәрләргә карата кызыксыну уяту, киләчәктә оешмаларга кирәк булган хезмәт иляәре турында әңгәмә үткәрү, укучыларга берникадәр һөнәри юнәлеш бирү кебек эшләр башкарылды. Класс җитәкчеләре класс сәгатьләрендә "Мин һәм минем һөнәрем", "Мин кем булырга телим?", "Әтиләр эшен дәвам итәбез", "Һөнәрле үлмәс,һөнәрсез көн күрмәс" һ.б. темаларга төрле чаралар үткәрделәр.

Укытучы тарафыннан ныклы караш, күп көч сорый торган юнәлеш – әхлак тәрбиясе.

Бу уңайдан мәктәпнең тәрбия планында төрле кичәләр урын алган:

Тәрбия дәресләре –

"Яхшы кеше нинди була?", "Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул яман" һ.б.

Бәйрәмнәр –

Әниләр көне;

Укытучылар бәйрәме;

Гаилә көне;

Студентлар белән очрашулар;

Укучыларда халык традиияләрен саклау максатыннан –

"Нәүрүз" кичәсе, "Сөмбелә" бәйрәме, татар шагыйрләренең туган көннәре олылап билгеләнә.

Тукай көннәре.

Барлык үткәрелгән тәрбия эшчәнлеге нәтиҗәсе укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсендә чагыла. Әлеге юнәлешләрне, үткәрелгән чараларны истә тотып, 1-9 классларда класс җитәкчеләре тарафыннан укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсе билгеләнде. Әлеге эштә укучыларның укуга, хезмәткә, гомуми чараларга, дусларга, спортка мөнәсәбәте исәпкә алынды.

Тәрбия эшчәнлегенең мавыктыргыч юнәлеше – эстетик юнәлеш. Төп бурычлары булып, мәктәпнең, классның иҗади эшчәнлегенә укучыларны тарту, буш вакытларын кызыклы, файдалы итеп үткәрүләренә ирешү, эстетик сыйфатлар, зәвык, сәнгатьтә һәм тормышта гүзәллекне аңлый һәм тудыра белү,тормышны матурлык кануннары нигезендә кора белү сыйфатлары формалаштыру тора.

Бу юнәлештә укучыларны җәлеп иткән төп чараларга

- походлар;
- музейларда булу;
- сәнгать кешеләре белән очрашулар;
- төрле бәйрәмнәр үткәрү керә.

Укучыларыбыз җыр-биюгә, шигырь сөйләргә бик оста. Араларында район сәхнәләрендә үз сәләтләрен күрсәткән һәм уңышларга ирешкән укучыларыбыз да бар. Районда үткән "Йолдызлык – 2015" фестивалендә актив катнашкан бию коллективы грамота белән бүләкләнде. (Җитәкчеләре Петрова Г.Н., Антонова Н.Г.) Мәктәптә уку елы барышында укучылар көче белән әзерләнеп бик матур концертлар куелды.

Экологик юнәлешнең төп бурычы табигатьне аңларга, яратырга өйрәтү , укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. Бу юнәлеш буенча мәктәптә максатчан һәм экологик программа нигезендә эш алып барылды. Сентябрь аенда "Планетаны чүптән чистартыйк" акциясе кысаларында Чисталык дәресләре үткәрелде. Эш планы төзелде һәм мәктәптә күп төрле чаралар үтте. Ә март ае тулысы белән табигать ае дип игълан ителде һәм укытучылар балалар белән "Урман көне"н билгеләп үттеләр. Башлангыч сыйныфлар атналыгы да экологик тәрбиягә багышланган иде. Бу класс җитәкчеләре кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, "Кошлар – безнең дусларыбыз", "Су – яшәү чыганагы", "Урман сукмагы буйлап", "Чәчәкләр бәйрәме" кебек класс

сәгатьләре үткәрделәр. Май аенда мәктәбебез укучылары агач утырту акциясендә катнашып, 900 агач утыртты.

Тәрбия системасының мөһим тармакларыннан берсе укучылар үзидарәсе һәм укучылар оешмасы эшчәнлеге. 2014-2015 нче уку елында “Хыял” укучылар оешмасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләде:

- хезмәт юнәлеше ( макулатура, бөре, нарат күркәсе җыю)
- кайгырту юнәлеше (тимурчылык эше, өлкәннәргә шефлык)
- иҗадилык юнәлеше
- лидерлык юнәлеше (укучылар үзидарәсе эшчәнлеге, класс активларының эшчәнлеге, анкеталар алу, сайлаулар уздыру, вожатыйлар эшчәнлеге). Югары класс укучыларыннан торган үзидарә төрле бәйге-кичәләрдә, мәктәп күләмендә үткәрелә торган конкурс- акцияләрдә активлык күрсәтте. Мәктәп тормышында үткәрелә торган традиион бәйрәмнәрне үткәрү тәртибе үзидарәдә каралды, членнарның фикер-планнары кабул ителде.

Укучыларның буш вакытларын файдалы уздыру өчен шартлар тудырылган. Мәктәбебездә спорт мәктәбеннән 2 секция, тәрбия үзәгеннән 2 түгәрәк, мәктәп каршында 3 түгәрәк эшләде.

Уку елы дәвамында эти-әниләр белән эш алып баруда түбәндәге бурычлар куелган иде:

1) Һәр гаиләдә балаларны тәрбияләү системасын өйрәнү;

2) эти-әниләр белән берлектә укучыларның сәләтләрен ачыклау һәм үстерү өстендә эшләү

3) эти-әниләрнең мәктәп тормышына актив катнашуына ирешү.

Алынган бурычлар тулысынча үтәлде дип әйтергә була. Ел буена үткәрелгән тәрбия чараларында эти-әниләр актив катнашырга тырыштылар. “Әниләр бәйрәме”, “Әтиләр кичәсе” кебек мәктәпкүләм чаралар үткәрелде. Декабрь аенда “Гаилә бәйрәме” авыл мәдәният йортында узды. Һәр сыйныфтан берәр гаилә чыгыш ясап, үзләренең һөнәрләрен, җырга, биюгә осталыкларын күрсәттеләр, шулай ук гаилә шәҗәрәләре белән таныштырдалыр. Шушы бәйгедә җиңеп чыккан Васильев Илвир абый гаиләсе районадагы финал бәйгесендә катнашып республикада үтә торган “Гаилә бәйгесенә” чакыруга ия булдылар. “Классларда ата-аналар укуы системалы рәвештә алып барылды. Ата-аналар җыелышларында балаларның педагогик - психологик үзенчәлекләрен өйрәнү, кызыксынучанлыкларын һәм сәләтләрен ачыклау буенча эш алымнары белән таныштыру, гаиләдә әхлаклылык торышы, сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше темаларына сөйләшүләр үткәрелде. “Путь к успеху” республика программасы буенча ата-аналар укуы, тематик әңгәмәләр, анкеталар үткәрелде. Ата – аналар арасында балаларның наркотик матдәләр куллануы профилактикасы буенча аңлату эшләре алып барылды. Ел саен мәктәпнең социаль паспорты яңартыла. Әз керемле, “риск” төркемле, мөмкинчелеге чикләнгән, тулы булмаган, күп балалы гаиләләр төркеме ачыкланды.

Тәкъдимнәр:

1. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатыннан эти-әниләр, җәмәгатьчелек белән берлектә сәламәтлек көннәре үткәрү.

2. Укучыларның кызыксынучанлыкларын һәм сәләтләрен үстерү максатыннан төрле һөнәри конкурслар үткәрү.

3. Тәрбия бирүнең төрле ысулларын һәр дәрестә файдалану өчен укытучыга эзләнергә, иҗади табышлар кулланырга .

4. Укучыларны әхлакый яктан үстерү, тәрбиялелек дәрәҗәсен күтәрү.

Нәтиҗә:

Мәктәп укыту-тәрбия процессының бөтен баскычларында укучыларны укыту һәм тәрбияләүнең төп мәсьәләләрен үти.

**Психологик эшчәнлеккә анализ.**

Субаш төп мәктәбендә психологик ярдәм күрсәтү эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:

1. Психологик диагностика.
2. Укучылар, укытучылар, әти-әниләр белән консультация тибындагы индивидуаль сөйләшүләр.
3. Психологик профилактика.
4. Методик эшчәнлек.

Психологик диагностика юнәлешендә директор урынбасары Габитова С.И тарафыннан **I сыйныф** укучыларының адаптацион чор барышы тикшерелде. 2014-2015 нче уку елына I сыйныфка 4 бала килде. 4е дә малайлар. Балалар Субаш авылыннан килеп тупланган. Класс җитәкчесе- Гильфаова Нурсия Фарук кызы. Укучылар мәктәпкә әзерлек дәрәҗәләре буенча бертөрлерәк. Укучыларның һәрберсе белән индивидуль сөйләшү уздырылды, анкеталар тутырылды.Сөйләмнәре ачык, хәрефләрне төгәл итеп әйтә беләләр.

Мәктәпкә әзерлек дәрәҗәләре бик яхшы булган укучылар : Иванов Игорь, Гильмуллин Хәлим;

Әзерлек дәрәҗәләре яхшы укучы: Степанов;

Әзерлек дәрәҗәләре түбәнрәк_ булган укучы: Прокопьев .

Фигуралар ярдәменә укучыларның характер үзенчәлекләре билгеләндне. 2 укучы очпочмак сайлап лидерлар рәтенә керде, 2 укучы турыпочмаклык сайлап тормыштан канәгать икәнен белдерде. Эзлеклелек буенча хикәя төзү эшен балалар бик теләп башкардылар.

Хәреф танымаучы балалар юк, әмма барлык хәрефне дә белүче балалар аз. Укырга кергәннән соң математика фәненнән авырдан үзләштерүче бала: Прокопьев. Аналогияләр буенча эшне барлык укучылар аңлап башкардылар.

Укучылар мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләрен үзләштереп киләләр. Укытучыны тыңлый беләләр, үзләре бик хәрәкәтчәннәр, тереләр.Тәрбияче белән контактлары яхшы. Әти-әниләрнең дә мәктәп тәртипләрен кабул иткәннәре сизелеп тора, балаларының укырга теләп килүләрен әйтә.

Тәкъдимнәр:

1. Мәктәп кагыйдәләрен ныгытуны дәвам итәргә.
2. Балаларда өлкәннәрне тыңлау сәләтен үстерергә.
3. Балаларның үз-үзләрен укучы кебек итеп тоту өстендә эшләргә.

1 нче сыйныф укучыларының мәктәпкә әзерлек нәтиҗәләре.

| | 2012-2013 | | 2013-2014 | | 2014-2015 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бала саны | % | Бала саны | % | Бала саны | % |
| Яхшы әзерлек | 3 | 43 | 1 | 17 | 2 | 50 |
| Уртача әзерлек | 3 | 43 | 3 | 50 | 1 | 25 |
| Уртачадан түбән әзерлек | 1 | 14 | 2 | 33 | 1 | 25 |
| Түбән әзерлек | - | - | - | - | - | - |




Саннардан күренгәнчә, I сыйныф укучыларының мәктәпкә әзерлек дәрәҗәләре алдагы ел белән чагыштырганда  начар түгел.
Диагностика юнәлешендә шулай ук 5 нче класс укучыларының адаптациясе һәм урта звенога күчү барышы тикшерелде. 2014-2015 нче уку елында бишенче сыйныфка барлыгы  10 бала килде. 1 укучы малай Нәбиев Фәндүс өендә укытылды.Шуларның 4се малай, 6 кыз. Укучылар Субаш, Түбән Субаш  авылларыннан тупланган. Бишенчеләр белән, укуга карашны билгеләү максатыннан, мотивацион тест алынды. Нәтиҗәләре түбәндәгечә:

V сыйныф укучыларының  мотивацион тест нәтиҗәләре.

| Укучыга караш | 2011-2012 | | 2012-2013 | | 2013-2014 | | 2014-2015 | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бала саны | % | Бала саны | % | Бала саны | % | Бала саны | % |
| Укуга уңай караш | 7 | 58 | 10 | 83 | 7 | 70 | 7 | 77 |
| Аралашу өчен килүчеләр | 2 | 18 | 1 | 8.3 | 2 | 20 | 1 | 11 |
| Авырлык кичерүчеләр | 2 | 18 | 1 | 8,3 | 1 | 10 | - | - |

**Нәтиҗә:** 2014 нче уку елында урта классларга  килүче балаларның укуга карашлары яхшы, әмма аралашырга килүче укучы  булу да борчый. Авырлык кичерүче бала булмады.
Укучылардан алынган анкеталар түбәндәгене күрсәтте. 2 укучының рус телен, 1 укучының литература, 4 укучының татар теле,  5 укучының математика  фәннәрен яратулары, кызыксынып укулары ачыкланды. Кайбер фәннәрне мәсәлән, физкультура, рәсем  -1әр укучы яратмауларын язды. Шулай да класста кызыксынып укучылар күбрәк.

Шулай ук **бишенче сыйныф** укучылары белән “Мәктәпкә караш” анкетасы уздырылды. Нәтиҗәләре түбәндәгечә. Катнашты : 9 бала.

1. Мәктәптә миңа иң ошаган урын.

“Барысы да” – 9 бала җавап биргән.
“Спортзал, ашханә” – 4 укучы җавап биргән.

2. Мәктәптә миңа ошаган дәресләр.

Татар теле – 4 укучы.
Рус теле – 2 укучы.
Математика-5

3. Өй эшләрен башкарганда 7 укучы өлкәннәр ярдәме белән әзерлибез дигәннәр. 2 укучы мөстәкыйль дип язган.
4. Укытучылар минем укуым турында нинди фикердә?

4 укучыга тырышырга дип әйткәннәр.
4 укучыга молодец дип әйткәннәр.
1 укучыга тырышмыйсың дип әйткәннәр.

5. Әти-әниләрем мәктәп турында:

еш -7 укучы
сирәк - 1 укучы
беркайчан - 1 укучы сөйләшмиләр.

6. Мәктәптә минем укуым турында әти-әниләремнең фикере.

9 укучыга тырышырга кушылган.

7. Дүртенче класста укуым искә төшсә:

бишенчедә уку ошый дип 9 бала әйткән.

**Нәтиҗә:** 5 класс укучылары адаптацион чорны әйбәт үткәреп киләләр, укучыларда укуга карата уңай караш, кайберләренә тырышлыкларын арттырасы бар. Аерым игътибарга алынырга тиешле укучылар турында класс җитәкчеләренә җиткерелде. (Ахметшин Рәлиф, Иванов Сергей, Габделхаков Риназ) Укучылар урта звенода укуларын дәвам итәргә сәләтле, фән укытучылары белән мөнәсәбәтләре яхшы.

**Тугызынчы сыйныф** укучыларының һөнәри юнәлештә планнарын билгеләп, профиль классларына бүленеше буенча диагностик эш башкарылды.
Уздырылган методика: Е.Климов «Я предпочту», темперамент билгеләү, фикерләү төрләрен ачыклау.
Нәтиҗәләр түбәндәгечә:
Климов методикасы буенча 19 укучының «Кеше - Кеше» тибына 10 укучы, «Кеше - Техника» тибына 5 укучы, «Кеше - Сәнгать өлкәсе» тибына 2 укучы, «Кеше - Табигать» өлкәсе тибына 1 укучы, «Кеше – Билгеләр системасы» өлкәсенә 1 укучы керә.
Темпераментны билгеләү буенча сангвиник төренә 7 укучы, флегматикка - 6, холерикка - 3, меланхоликка 3 укучы туры килгәне ачыкланды.
Фикерләү тибын ачыклау тестында предметно-действенное төренә 4, абстрактно-символическое төренә 4, словесно-логическое төренә 2, наглядно-образное төренә 4, креативное төренә 5 укучы туры килә.

**Тәкъдимнәр:**

1. Уздырылган диагностикаларның нәтиҗәләрен профиль классларына бүленеш вакытында башка мәктәпкә күчкәндә исәпкә алырга ;
2. Профиль классларына киткәндә укучыларның кызыксынуларын, теләкләрен һәм сәләтләрен күздә тотарга киңәш бирергә;

Шулай итеп, укучыларның анкеталарына йомгак ясаганда игътибарга алынырга тиешле фактлар: укучылар профиль класслары кирәк икәнен әйткәннәр. Авырлык кичерүче балалар белән сәбәпләрен ачыклау булды, бу укучылар турында класс җитәкчеләренә, фән укытучыларына җиткерелде. Укучылар тормыштагы байлыкларны дөрес итеп күзаллый беләләр, өй эшен әзерләүгә киткән вакытны реаль файдаланалар. Аерым фәннәр буенча тырышып укучы 19 бала да укуның бурыч икәнен аңлап башкаралар. Алдагы планнарын күздә тоткан вакытта укучылар укуларын төрле уку йортларында дәвам итәчәкләрен белдергәннәр. Димәк, профиль класслары ачу укучыларга үзләрен танып белергә һәм төпле белем алырга мөмкинлек бирә.
Әти – әниләр, укытучылар, укучылар белән консультация, индивидуаль сөйләшүләр алып барылды. Баланың үз-үзен тотышы, гаиләдәге мөнәсәбәтләре, тәртибе, ул чыгарган конфликтлар анализланды.

Психологик профилактика максатыннан эти-әниләргә “Хәвефлелелек (тревожность) һәм аның сәбәпләре”, “Адаптация чоры авырлыклары” темаларына чыгышлар ясалды.

Район социаль яклау бүлегеннән дә килеп, чыгарылыш укучыларына, укытучыларга, лагерь балаларына психологик тренинглар үткәрелде.

Психологик ярдәм күрсәтү юнәлешен канәгатьләнерлек дип бәяләргә.

**Алдагы уку елында (2015 – 2016 нче ел)** класс җитәкчеләре белән эшчәнлекне ныгытырга, тәрбиягә авыр бирелүче балалар белән эшне көчәйтергә, “Путь к успеху” программасы нигезендә эшчәнлекне һәм суицидка, наркотикларга каршы профилактика эшен алып барырга.

**Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча эшчәнлеккә анализ**

2014-2015 нче уку елында материаль-техник базаны ныгыту буенча түбәндәге эшләр башкарылды:

Узган уку елы башында уздырырылган педагогик киңәшмәдә мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча коллектив алдына түбәндәге бурычлар куелган иде:

- дәүләт тарафыннан бирелгән интерактив такталар кайтарту;
- парталар яңарту;
- 1 кабинетка ремонт үткәрү.

Планлаштырган бу эшләрнең үтәлеше түбәндәгечә булды:

Һәр кабинеттан интернет челтәренә кереп эшләрлек Wi-Fi системасы эшләде. Мәктәптә 5 экран, 5 видеопроектор булуы да дәресләрдә интерактив методларны киңрәк куллануга мөмкинлек тудыра. Гомумән, хәзер безнең барыбызга да комьютер технологияләрен өйрәнергә һәм тиешле моментларда куллана белергә кирәк.

Барлык уку кабинетларында, лабораторияләрдә, ашханәдә электр үткәргечләрнең һәм приборларының төзеклеге тикшерелде.

Методик кабинет өчен һәм имтиханнар турында информация өчен методик стенд яңартылып барыла.

Үз көчебез белән 72 мең сумлык акча эшли алдык.

Мәктәпнең нормаль эшчәнлеген алып бару өчен көндәлек акча кирәк. Муниципаль район бюджетыннан хезмәт хакы, коммуналь хезмәтләр (мәктәпне җылыту, электр энергиясе, су, канализация, өзеклекләр белән булса да телефон), автобусларга бензин өчен акча бүлеп бирелә. Ә бит башка чыгымнар да бар. Мәсәлән, кәгазь, акбур, электр лампочкалары, принтерларга тонер, савыт-саба юу сыеклыклары, савыт-саба, һәртөрле хуҗалык кирәк-яраклары, төрле дәүләт оешмаларында документлар эшләтү өчен пошлиналар…

Ел дәвамында акча кертү юллары:

1. Ел буена 1500 мең сумлык макулатура җыелды.
2. 1 мең сумлык орлык чәчтек. Калган орлык үзебез әзерләгән. Алынган уңыш түбәндәгечә булды:

- суган - 180 кг.
- чөгендер – 900кг.
- кишер – 920 кг.
- кәбестә – 1080 кг.
- карлыган, чия, алма суытылып катырылды
- тозланган яшелчә- 180 литр,
- киптерелгән алма – 40 кг.
- катырылган җиләк-җимеш- 80 кг.
- варенье- 20кг

Яшелчә һәм җиләк-җимешләр сату 40 меңлек булды.

Җәен барлык уку кабинетлары, спортзал, тәрәзә төпләре буятылды, география кабинетына 1 такта кайтарылды, Тарих кабинеты ремонтланды. Бәрәңге подвалы агартылды. Ясаган ремонтны «Белем» бәйрәмендә катнашкан эти-әниләр уңай бәяләде.

Хәзер мәктәпне, мебельләрне, җиһазларны саклап тоту- беренче чиратта торган уртак бурычларыбызнын берсе.

Мәктәпкә 1 кабинетка парта, урындык, җылыту системасын алмаштыру планлаштырыла.

# Балтач районы Субаш төп гомуми белем мәктәбе китапханәсенең 2014-2015 уку елындагы эшчәнлеге турында анализы

Мәктәпне китапханәсез күз алдына китерүе кыен. Мәктәп китапханәсе һәр укучы һәм укытучының төп таяну ноктасы булып тора. Белешмә сүзлекләр. Методик ярдәмлекләр, матур әдәбият, вакытлы матбугат чаралары- һәммәсе бүгенге укучыга багышлана.

Китапханә ул - мәктәп терәге, ә мәктәп - белем йорты. Мәктәп китапханәсе укчыларны белемле итүдә зур роль уйный. Белемнең күп өлешен укучы үзлегеннән китаплардан ала. Китапханәгә кергән һәр мәктәп кешесенең ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырышам. Кайткан китаплар белән эшлим, информацияләр бирәм. Күргәзмәләр куям.

Әдәби китаплар, газета- журналларны ике китапханәдән дә алалар, укыйлар. Мәктәп китапханәсеннән бигрәк тә балалар “Күчтәнәч”,”Сабантуй” һәм “АБВГД” журналларын яратып укыйлар. Китапханәдә бик күп мәгълүмат, аң-белем тупланган. Киләсе елга вакытлы матбугат, газета- журналларга заказлар алынды, алар электрон почта белән җибәрелә. Беренче сыйныфка укырга кергән укучыларны китапханә белән таныштыру күздә тотыла. Бу- укучыларны тартуның иң отышлы чарасы. Беренче сыйныф укучыларын дәресләрендә балалар китаплары белән таныштырдым, алар турында сөйләдем. Табышмаклар әйтештек. Хайваннар турында сөйләштек.

Субаш урта мәктәбе китапханәсе 2014-2015 уку елында педсоветта расланган эш планы нигезендә эшләде. Китапханәдә барлыгы 16079 китап бар. Шуның эченнән 1702 е дәреслекләр. 13941 сы матур әдәбият, калганнары методик әдәбият һәм фәннәр укыту буенча методик журналлар булып тора. Мәктәптә барлыгы 21 укытучы һәм 11 техник персонал эшли. Укучылар саны 90 Барлык укучылар, укытучылар һәм техник работниклар китапханәдән файдаланалар һәм аның даими укучылары булып торалар.

Китапханәче Фаезова Эльмра Мисаел кызы, 1972 елда туган, махсус урта белемле, мәктәп китапханәчесе буларак эш стажы 5 ел. Китапханәнең уку залы, китаплар һәм дәреслекләр саклау бүлмәләре бар. Китапханәнең уку залы якты бүлмәдә урнашкан.

Укучылар китапханәгә даими йөриләр. Үткән уку елында бер укучыга уртача 10-12 китап алынган. Көн саен китапханәгә уртача 25-35 китап укучы керә. Алар китаплар алалар, төрле белешмәләрдән, энциклопедияләрдән файдаланалар. Газета-журналлар укыйлар.

Китапханәгә кайткан китаплар даими рәвештә учетка алып барылды. 2014-2015 уку елында гамәлдән чыккан дәреслекләр списать ителде. Яңа кайткан китаплар укучылар алдында һәм укытучылар алдында даими пропагандаланды. Яңа кайткан китаплардан китап күргәзмәләре эшләнде.

Укучылар белән план нигезендә тәрбия темасына әңгәмәләр үткәрелде. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына карата  укучылар белән тәрбия беседалары үткәрелде, 70 еллыкка төзелгән чаралар планы буенча эшләдем. Укучыларга “Ленинград блокадасы” татар телендә презентация һәм әңгәмә үткәрелде.Югары сыйныф укучыларына “А зори здесь тихие” фильмына, А.Фадеевның “Молодая гвардия” китапларына буктрейлерлар күрсәтелде. Сыйныф җитәкчеләре белән бергәләп кичәләр үткәрелде. “Җәлилчеләр”, “Муса Җәлил – герой шагыйрь” – библиографик дәресләр уздырдым.  Авылыбызның сугыш чоры балалары белән түгәрәк өстәл үткәрелде.Сугышта һәлак булган һәм исән кайткан шагыйрьләргә багышланган “Каләмне корал итеп” дип исемләнгән стенд ясадым.

Беренче сентябрь көнне “Белем бәйрәме” көне уңаеннан китап күргәзмәсе куелды. Сентябрь  аенда шулай ук 2-3-4 сыйныф укучылары белән дә һәр сыйныфта аерым аерым китапханә эшчәнлеге белән таныштыру  буенча әңгәмәләр үткәрелде. Сентябрь аенда һәр класс укучыларын дәреслекләр белән тулысынча тәэмин итү буенча күпкырлы эш алып барылды.Барлык сыйныф укучыларын да  дәреслекләр белән тәэмин иттек.

Китапханә эше, аны һәрьяклап яхшыртуны таләп иткән төп документлар  нигезендә оештырылды. Китап пропагандалау аша укытучылар коллективына укыту-тәрбия эшен оештыруда үз белемен күтәрүдә ярдәм итү буенча билгеле бер күләмдә эш башкарылды. Иҗтимагый-фәнни популяр һәм матур әдәбиятны даими пропагандалау буенча эш алып барылды, әңгәмәләр үткәрелде.

Укучыларга библиография нигезләрен өйрәтү, аларда әдәбият ярдәмендә үзлегеннән белем алу, уку культурасы күнекмәләре тәрбияләү буенча даими эш алып барылды. Татар әдәбияты һәм сәнгатенең бөек шәхесләре юбилейлары уңаеннан мондый зур даталарга багышлап китап күрәзмәләре оештырып, укытучыларга тәрбия беседалары үткәрүгә булышлык ителде.

Рус һәм татар язучыларының туган көннәрен билгеләп, укучылар белән тәрбия беседалары үткәрелде, китаплар сайларга булыштым. Яңа кайткан дәреслекләрне һәм матур әдәбиятны компьютер программасына кертү эшен өйрәнү һәм алып бару буенча эш дәвам ителде.

Уку елы башында ук барлык укучыларның да мәктәп һәм авыл китапханәсенә язылуына ирешелде. Авыл китаханәсе Габделхакова Лидия  белән даими рәвештә элемтәдә булдым. Укучыларның  анда йөрүләре белән танышып бардым. Өлгереше түбән һәм узган уку елына китапханәгә  аз мөрәҗәгать иткән укучыларны даими китап укуга  тарту  буенча индивидуаль эш алып бардым. Укучыларның китап укуларына юнәлеш бирелде, аларның нәрсә белән кызыксынуын, ничек укуларын өйрәнү масаты белән әңгәмәләр уздырылды. Укытучылар белән бергәләп, төрле темаларга, яңа китапларга әдәдбияткә күзәтүләр ясалды, газета-журнал материаллары турында әңгәмәләр  уздырылды  Укучыларның рус һәм татар әдәбияты, шулай ук башка фәннәрдән класстан тыш уку өчен тәкъдим ителгән китапларны

уку өчен китап сайларга булыштым. Класс җитәкчеләре һәм аерым фән укытучылары белән берлектә һәр класста укучыларның китап укуына анализ ясалды. Аның нәтиҗәләре турында педсоветта информация ясалды.

Укытучылар коллективына сәхнәләштерү өчен спектакль сайлау.

Яңа кайткан дәреслекләргә инвентаризация.ЭС ЭФУЛ га кертү.

Истәлекле даталарны яктыртып бару

«Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп»кә язылу

Тукайга карата стендлар булдыру

Җиңү көнен билгеләп үтүдә булышу

2 нче яртыеллыкка сыйныфтан тыш уку буенча нәтиҗә ясау.

Сыйныфлар буенча дәреслекләрнең чисталыгын тикшереп туплау.

Китапханә отчетын эшләү

Рус һәм башка татар язучыларының туган көннәре дә билгеләп үтелде. Бу даталарга карата китап күргәзмәләре оештырылды.

Районыбызда иҗат итүче якташларыбызның китапларыннан зур китап күргәзмәсе оештырылды.

Китапханә - серләр дөньясы. Изге фикерләрнең чишмә башында торучы. Китапханә китап киштәләрендә тезелеп торучы китаплары белән түгел, ә укучылары белән яши. Шулар белән матур.

Мәктәп директоры: ______________ (Галиева Р.М.)

Мәктәп китапханәчесе: _____________ (Фаезова Э.М)

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
«Субаш төп гомуми белем мәктәбе»

# 2014-2015 нче уку елында башлангыч сыйныф укытучыларының методик берләшмәсе башкарган эшчәнлегенә анализ.

Төзеде:
1 нче квалификацион категорияле
башлангыч сыйныфлар укытучысы
Гыйльфанова Нурсия Фарук кызы

**2015 нче ел.**

**Методик берләшмәнең узган 2014-2015 нче уку елындагы эшчәнлегенә анализ.**

Субаш төп гомуми белем мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучылары берләшмәсе 2014 – 2015 нче уку елында уку елы барышында төзелгән план нигезендә укучыларга яңа технологияләр кулланып, ныклы белем һәм күнекмәләр бирү, укыту методларын һәм чараларын камилләштерү, иҗат лабараторияләрен баету, тулыландыру юнәлешендә эшләде. Башлангыч сыйныф укытучылары ”***Яңа технологияләр нигезендә белем сыйфатын үстерү”*** дигән тема өстендә эшли башлады.

Берләшмә утырышларында «Укучыларның танып белү активлыгын үстерү», «Яңа стандартларга күчкәндә», «Кече яшьтәге мәктәп балаларының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту» темаларына чыгышлар һәм фикерләр тыңланды.

1 нче класста беренче категорияле укытучы Гыйльфанова Нурсия Фаруковна укытты. Балалары һәр үткәргән чарада бик актив катнаштылар. Әти-әниләр өчен “Әлифба”бәйрәме ,ачык дәрес үткәрде. Өлкәннәр көнендә бик матур кичә һәм концерт күрсәттеләр.Районнын озынайтылган көн группасы тәрбиячеләренә дуслык турында ачык тәрбия сәгате күррсәтте. Укучылары “Осень 2014”,”Зима 2015”интернет олимпиада да катнашып 1нче дәрәҗәдәге һәм 2 нче дәрәҗәдәге дипломга лаек булды. Укытучысы рәхмәт хаты белән бүләкләнде. 3 укучысы “Сократ” олимпиадасында катнашып 1 нче һәм 2 нче дәрәҗәдәге диплом,укытучысы рәхмәт хаты белән бүләкләнде.. “Провнуки рисуют дедов” рәсем конкурсында Прокопьев Владислав диплом, “Бозда куркынычсызлык кагыйдәсе”рәсем конкурсында Гыйльмуллин Хәлим сертификат белән бүләкләнде.Гыйльфанова Нурсия Фаруковна үзе юл йөрү кагыйдәләренә багышланган кичәдә Балтач районы ГИБДД җитәкчесе Ф.Т.Шәфигуллинның рәхмәт хатына лаек булды.Укчылары иҗат концертына бик ныклап әзерләнделәр. Балалар барысы да катнашты.

2 нче класста югары категорияле укытучы Закиров Фарит Масхудович укытты.Балалары һәр үткәргән чарада бик актив катнаштылар. Яна ел бәйрәмендә бик матур әдәби-музыкаль кичә күрсәттеләр.Укучысы Нуриев Рәниф “Алтын көз”конкурсында катнашып дипломга,ә Фәрит Мәсхудович үзе рәхмәт хаты белән бүләкләнде. “Форпост 70 еллык “ конкурсында командасы
2 нче урынны алды һәм грамота белән бүләкләнде.. Хәрби спорт уеннары “Аҗаган”да катнашып командасы 1 нче урынны алды һәм грамота бирелде.Юлда йөрү кагыйдәләре буенча оештырылган кичәдә рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Укучысы Ризванов Әнискә “Бозда куркынычсызлык кагыйдәсе” буенча рәсем конкурсында катнашканы өчен сертификат бирелде.
Васильева Ильвина,Вафина Илсинә,Камалиева Ризәлә “Әнием күңелем түрендә”дигән рәсем конкурсында катнаштылар һәм рәхмәт хаты бирелде.Гафурҗанова Зилә” Парламент дәресләре”рәсем конкурсында конкурсында катнашып 3 нче урынны алды ,грамота бирелде.Васильева Ильвиналар гаиләсе”Күркәм гаилә”район бәйгесендә катнашып Казанда уздырылачак турга үттеләр.
Иҗат концертына бик ныклап әзерләнделәр.Балалар барысы да катнашты.Белем бирү сыйфаты **50%.**

3 нче класста югары категорияле укытучы ВасильеваГөлназ Фазыловна укытты..Балалары һәр үткәргән чарада бик актив катнаштылар. Яна ел бәйрәмендә бик матур әдәби-музыкаль кичә күрсәттеләр. Укучысы Гильманова Зәлидә”Мой дом-моя Республика”дигән рәсем конкурсында сертификат алды.Укучылары Нурмөхәммәтов Дилүс, Васильева Ильвина татар

теленнән интернет –олимпиада да катнашып  диплом  белән, ә Гөлназ Фазыловна үзе рәхмәт хаты белән бүләкләнде. “Наз “ социаль үзәк үткәргән”Әнием –күңелем  түрендә” конкурсында Хәкимова Язилә рәхмәт хаты алды. “Провнуки рисуют дедов” рәсем конкурсында Гафурҗанова Зифа диплом, “Бозда куркынычсызлык кагыйдәсе”рәсем конкурсында Хәкимова Язилә сертификат белән бүләкләнде.  Татар балалары иҗатының дистационконкурсында Иванов Альфир диплом, Хәкимова Язилә,Нурмөхәммәтов Дилүс сертификат, Россиякүләм “Родная речь” әдәби конкурсында Васильева Ильвина лауреат Дипломы, Республикакүләм Афзал Шамов исемендәге  конференциядә шулай ук  Васильева Ильвина 2 нче урынн алды. Ә Гөлназ Фазыловна үзе “ Гаилә  һәм мәктәп” журналының дипломы,Балтач муниципаль район башлыгының Дипломы “ Гаилә-дәүләт нигезе” республика конкурсының муниципаль этабы җиңүчесе, Казанга   финалга чакыру алды.,Ел сыйныф җитәкчесе” муниципаль этапта “Иң яхшы проект” номинациясе.1 нче республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә 3 нче дәрәҗә диплом, ФГОС кысаларында сәләтле балалар белән эшне оештыру” темасына ясаган доклад өчен сертификат, юл йөрү кагыйдәләренә багышланган кичәдә  Балтач районы ГИБДД җитәкчесе Ф.Т.Шәфигуллинның рәхмәт хаты белән бүләкләне.
Иҗат концертына бик ныклап әзерләнделәр.Балалар барысы да катнашты.Белем бирү сыйфаты **57%.**

4 нче класста югары  категорияле укытучы  Антонова Нәфисә Гарифулловна укытты. Балалары һәр үткәргән чарада бик актив катнаштылар.Өлкәннәр көнендә бик матур кичә һәм концерт күрсәттеләр. Укучысы Фролова Миләүшә “Провнуки рисуют дедов” рәсем конкурсында 2 нче урынны алды диплом белән һәм  “Бозда куркынычсызлык кагыйдәсе”рәсем конкурсында сертификат белән белән бүләкләнде. Шулай ук Фролова Миләүшә антикорупциягә каршы  “Надо жить честно “дигән аппликация конкурсында диплом белән һәм “Урман уттан курка “дигән рәсем конкурсында сертификат белән бүләкләнде.Укучылары   “Созвездие-Йолдызлык-2015” конкурсының “Хореография” номинациясендә диплом белән бүләкләнделәр. Антонова Нәфисә Гарифулловна үзе “Яхин укулары” I республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә уңыш казанган өчен III дәрәҗә диплом һәм районның башлангыч сыйныф укытучылары арасында “Методик капилка “конкурсның “ Иң яхшы дидактик материал” номинациясендә җиңүче булды. Юл йөрү кагыйдәләренә багышланган кичәдә  Балтач районы ГИБДД җитәкчесе Ф.Т.Шәфигуллинның рәхмәт хатына лаек булды.
Укчылары иҗат концертына бик ныклап әзерләнделәр. Балалар барысы да катнашты. Белем бирү сыйфаты 63 %   булды.

Югарыда санап кителгән һәр укытучының эш төре укыту процессында укчыларны активлаштыруда киң кулланылды.

2014-2015  нче уку елында башлангыч сыйныф укытучыларының методик берләшмәсе түбәндәге бурычларны хәл итү өстендә эшләде.
1.Укучыларның белем стандартларын үзләштерү дәрәҗәсен тәэмин итү, мөстәкыйль фикерләү дәрәҗәсен үстерү;
2.Предметара бәйләнешләрдән файдаланып, укучыларда экологик күзаллаулар формалаштыру;
4. Проект технологиясен гамәлдә актив куллану;
4.Компьютер технологиясен куллануны камилләштерү;

Шушы бурычларны үтәү өчен,башлангыч сыйныф укытучылары ел дәвамында тырышып эшләделәр. Һәр укытучының бай иҗади лабораториясе тупланган. Аңа карточкалар, тестлар, таблицалар, перфокарталаркерә.

Берләшмәдә һәр укытучының мониторингы даими тулыландырыла.

***Киләсе уку елына бурычлар.***

1.Информацион һәм проект технологияләрен дәресләрдә куллануны дәвам итәргә;
2.Дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда милли төбәк компонентыннан файдаланырга;
3.Укучыларга китап укуны, иҗади хезмәтне даими йөкләргә.

МБ җитәкчесе: Гыйльфанова Н.Ф.

**Гуманитар фәннәр укытучылары методик берләшмәсенең 2014-15 нче уку елындагы эшчәнлегенә анализ.**

Укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрүнең төп шарты-мәктәптә системалы методик эшне оештыру. Бүгенге көндә, яңа методик алымнарны, технологияләрне, рациональ һәм зур тизлек белән үз эшендә куллану кирәк чорда, методик эшнең әһәмияте аеруча арта.

Берләшмәгә татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле, тарих һәм җәмгыять фәне укытучылары керә. Методик берләшмә “Укучы шәхесен һәрьяклап тәрбияләү һәм төпле белем бирүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдә заманча информацион технологияләр куллану” - дигән проблеманы ачу өстендә эшли.

Һәр укытучы үзенен индивидуаль методик темасы, педагогик технологиясе, ижади эш планы нигезендә эш алып бара. Уку елы дәвамында фәннәр буенча үткәрелгән ачык дәресләрдә тәҗрибә тупланылды, алдынгы технологияләр өйрәнелде, булган кимчелекләрне бетерү өстендә эшләнелде. Шулай ук фәннәрне авыр үзләштерүче укучылар белән эшләүнең төрле алымнарын файдалану ысуллары каралды. Методик берләшмә утырышларында бүгенге технологияләр, аларны куллану алымнарын өйрәнү буенча сөйләшүләр, фикер алышулар үткәрелде. Уку елындагы уңышлы яклар, йомгаклау контроль эше нәтиҗәләре - барысы да укытучының методик һәм педагогик осталыгын күрсәтә; киңәшләшеп, үзара ярдәмләшеп эшләүнең ни дәрәҗәдә булуын яктырта.

Укытучыларның уңышлары да күп. Төрле конкурс, бәйге, конференөияләрдә һәрдаим катнашып яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Васильева Г.Ф. ның укучысы Нурмухаметова Ә.А. (8 сыйныф) татар теле һәм әдәбиятыннан 3 нче Халыкара олимпиадасында 3нче дәрәҗә дипломга ия булды.Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Васильева Г.Ф. һәм Галиева Р.М. җитәкчелегендә 8 нче сыйныф укучысы Васильева Гөлинә “Ибраһим Хәлфин” исемендәге 10 республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясендә 3 урын- дипломга , 8 нче сыйныф укучылары Васильева Гөлинә һәм Нурмухаметова Әдилә “Алиш эзләреннән” исемендәге 1 төбәкара фәнни-гамәли конференциясендә 2 урын - дипломга ия булдылар.

Рус теле һәм рус әдәбияты укытучысы Хабибуллина В.А. ның 8 нче сыйныф укучысы Хабибуллина Азалия рус теле фәне олимпиадасының муниципаль этабында жинуче булды.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Габитова Сания Ильясовнаның укучысы Хадеева Линара "Алтын каләм" конкурсында муниципаль этапта призер булды һәм Бөтенрәсәй “Илхам” ижат бәйгесендә лауреат дипломы белән бүләкләнде. Укучылары төрле бәйгеләрдә муниципаль этапта призерлар.

Габитова С.И. һәм Васильева Г.Ф. “Яхин укулары” конференциясендә катнашып

3 нче дәрәҗә дипломга ия булдылар.

Нурмухаметова Ф.Н.ның укучысы - "Творите, что хотите" Бөтенроссия конкурсында 1 дәрәҗә дипломга ия булды.

Тарих укытучысы Николаев И.И. “Уроки жизни” район конкурсында катнашты. “За внимание и интерес к тем, кто трудится в сфере обслуживания” номинациясендә методик эшкәртмә белән 3 урын диплом белән бүләкләнде. «Виртуальная экскурсия по школьному музею» бөтенрәсәй конкурсында “Школьный музей как средство патриотического воспитания” номинациясендә 3 урын дипломга ия булды.

Рус теленнән 19 укучы төп дәүләт имтиханнарын яхшы гына тапшырдылар. Укытучылары Хабибуллина В.А. Татар теле фәненнән 9 нчы сыйныф укучылары бердәм дәүләт имтиханын тапшырдылар. Укытучылары Габитова С.И.  Нәтиҗәләре яхшы булды.

Уку елы ахырында укучыларның барысы да белем стандарты таләпләренә җавап бирерлек белем алды. Барлык фәннәр буенча уку программалары тулысынча үтәлде.

Киләсе елда берләшмә эшчәнлеген үстерергә, укытучылар бергә-бергә кулга кул тотынып эшләргә. ГИА га әзерләнүләрне дәвам итәргә, бу уку елындагы күрсәткечләрне сакларга, төшермәскә. Яңача укыту методларын дәресләрдә актив кулллланырга.

Берләшмә җитәкчесе:                                        /Нурмухаметова Ф.Н./

## Физкультура-технология методик берләшмәсенең 2014-2015 уку елындагы эшчәнлегенә анализ

Методик берләшмәнең темасы: Дәресләрдә инновацион технологияләрне киң куллану, балаларда иҗади фикерләү күнекмәләрен үстерү юлларын эзләү.

Шул максаттан, бер-беребезнең дәресләрендә булып тәҗрибә уртаклашабыз, мәгарифтә булган яңалыклар белән танышабыз һәм үзебезнең эшебездә кулланабыз.

Укыту һәм тәрбия эшен укучының сәләтен, мөмкинлеген, үзенчәлеген искә алып, аңа шәхси якын килеп оештыру уңай нәтиҗәләр бирә. Биремнәрне төркемләп, парларда эшләү яки фронталь эш белән чиратлаштырып алып барабыз. Ә иң мөһиме –укучыларда мөстәкыйль, иҗади эшли белү күнекмәсе формалаштыру өстендә эшлибез.

Безнең мәктәпнең физкультура – технология методик берләшмәсенең бурычлары:

- милли мәгариф һәм тәрбия буенча юнәлеш бирү;

- укыту программаларының үтәлешенә һәм аларның дәүләт стандартларына туры килүенә ирешү;

- сыйныфтан тыш үткәрелгән чараларның сыйфатын үстерү;

- методик эшне диагностик нигездә оештыру;

- укыту планнары һәм программалары нигезендә фәнни укытуга иҗади якын килү;

- авторлык программалары эшләү һәм Мәгариф һәм Фән министрлыгы , Мәгарифне үстерү институты оештырган конкурсларда катнашу;

- алдынгы тәҗрибәне республика, җирле матбугат, радио, телевидение аша тарату.

.Информацион-методик функцияләр:

– милли төбәк компонентын кулланып, иҗади якын килеп укыту процессын тагын да камилләштерү;

- укытучыларның фәнни-практик конференцияләрдә, семинарларда, педагогик укуларда, профессиональ мөмкинлекләрен күрсәтә торган конкурсларда катнашуын тәэмин итәргә, ярдәм күрсәтү;

- укытучыларның белем һәм методик осталыкларын үстерү, квалификацион категорияләрен күтәрү эшенә юнәлеш бирү.

ТИН дәресләрен Закиров Фәрит Масхудович укыта. Аның уку елындагы эш нәтиҗәләре:

“Лучший специалист по охране труда” конкурсында сертификат, Форпост отрядлары ярышында уңышлы чыгыш ясадылар, “Безопасное колесо” ярышларында катнаштылар. 2 сыйныфта янгын куркынычсызлыгына ачык тәрбия сәгатеүткәрде. Закиров Ф “Аҗаган” уеннарын да бик яхшы әзерлекле, мавыктыргыч итеп үткәрә.

Физкультура дәресләрен Загидуллин К.Г. укыта. Аның уку елындагы эш нәтиҗәләре:

“Осенний кросс”ХөснетдиноваА, Николаев Р- 2 урын, районда җиңел атлетика ярышында 8 нче сыйныф укучысы Нурмөхәмматова Ә 2нче урын.

Мини футбол кызлар-3 урын

Футбол малайлар -2 урын.

ГТО- Нәбиев Илсаф -1 урын.

Технология дәресләрен Фаязов Л, Фазов Ә, Фәезова Э укыталар.Алар Фаязов Л, Фазов Ә“Казанская чаша”күргәзмә ярминкәсендә катнаштылар.23 февраль, 8 -мартка әти- әниләргә бүләкләр ясаттылар.Районда үткәрелгән зур чараларда укучыларның кул эшләре күргәзмәләрен оештырдылар.

Музыка фәнен Фәезов Х.Р укыта. **.** Аның уку елындагы эш нәтиҗәләре:

- Почетная грамота министерства культуры РТ март 2014, -, Республика семинары(гөслә), Хезмәт газетасында мәкалә.Иске Казан түгәрәк уены татар фольклоры фестивале-1 дәрәҗә лауреат дипломы, Халыкара этник фестиваль«Крутушка» да катнашты.Укучылары «Голос-дети», «Шома бас» конкурсларында уңышлы чыгыш ясап дипломнарга ия булдылар.

Физкультура дересен Хөснетдинов Азат Альберт улы да укыта.

Биектау шәһәрендә уздырылган “Школа безопасности 2015” ярышларында катнашып түбәндәге урыннарга лаек булдылар:

“Тикшерү – коткару эше”дистанциясендә IV-урын, “Каршылык полосасы” дистанциясендә II-урын,

"Гомуми физик әзерлек" ярышларында II-урын,Янгын сүндерүчеләр поласасында II-урын,

Гомуми нәтиҗә дә III-урын.

28- 29 май көннәрендә районда туристик слет булып узды. Районыбызның барлык командалары да бу ярышта үз көчләрен төрле конкурсларда һәм туристик полосада сынадылар. Укучылар 3 көн буе табигать шартларында компьютер һәм телевизордан аерылып саф һавада күңелле ял иттеләр. Ел саен уздырыла торган әлеге туристик слетта укучылар бик теләп катнаша. Мәктәбебез командасы чыгышы түбәндәгечә бәяләнде.

- "Полоса препятствий"- 1 урын;

- "КТМ"- 1урын;

- Конкурс видеороликов "Наша команда" 1 урын._

- Гомуми нәтиҗә 1 урын.

**Төгәл фәннәр методик берләшмәсенең 2014-2015нче уку елындагы эшчәнлегенә анализ**.

Субаш төп гомуми белем мәктәбендә узган уку елында табигать фәннәре һәм математикадан 5 укытучы белем бирде: 5 укытучы да югары белемле; 2 укытучы югары квалификацион категорияле, 1 укытучы беренче категорияле, 2 укытучының квалификацион категорияләре юк.

Методик берләшмәнең проблемасы: “Интернет технологияләр ярдәмендә укучыларның иҗадилыгын үстерү.” 2014-2015нче уку елына түбәндәге бурычлар алынган иде: белем сыйфатын күтәрү, укучыларның иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү, сәләтле һәм фәнне авыр үзләштерүче укучылар белән эзлекле эш алып бару, укучыларны фәнни-эзләнү эшчәнлегенә тарту, конкурентлыкка сәләтле укучылар тәрбияләү. Алга куйган бурычларны тормышка ашыру максатыннан, укытучылар үз эшләрендә мәгълүмат технологияләрен уңышлы кулланып, уку-укыту процессын алып бардылар.

Укытучылар район, республика күләмендә үткәрелгән семинарларда да катнашып, үзләренең белем һәм тәҗрибәләрен үстерү өстендә эш алып бардылар.

Укытучылар тарафыннан мәктәптә күп кенә чаралар үткәрелде. Химия-биология укытучысы Сабирова Г.Р. мәктәп күләмендә кошлар көненә викторина, сыерчык оялары конкурсы үткәрде. Мәктәп күләмендә призлы урын алган сыерчык оялары район конкурсына җибәрелде. Укучыларның эшләре белән “Марш парков” акциясендә катнаштылар, укучылар Дипломнарга ия булдылар. Яшь укытучы булуына карамастан, Сабирова Г.Р. “Ел укытучысы” конкурсында катнашып, уңышлы чыгыш ясады.

Математика укытучысы Гарифуллин Р.Г. үзенең иҗади эше белән “Искусство обучать - 2014” методик эшкәртмәләр россиякүләм конкурсында катнашып, яхшы сыйфатлы эше өчен Мактау грамотасына лаек булдылар. Район күләмендә үткәрелгән фән олимпиадаларында актив катнаштык. Шулай ук дистанцион һәм интернет конкурсларда укучылар актив катнашалар. Мәсәлән, ”Меташкола”, "Пятнашки", “Судоку”, “Сократ” , “Крестики - нолики 15х15” һәм “Инфознайка.

Бүген өлкән классларда белем бирүне камилләштерүнең әһәмиятле юнәлеше – ОГЭ үткәрү. Бу уку елында математика, информатика фәннәреннән 9нчы сыйныф буенча имтихан нәтиҗәләре яхшы. Имтиханнарга әзерлек югары дәрәҗәдә алып барылды.

Мәктәп күләмендә 15.12.14 – 27.12.14 числоларында математика, физика, информатика атналыгы план нигезендә узды. Атналыкта математика укытучысы Гарифуллин Р.Г. тарафыннан “Мәсьәләләрне икенче дәрәҗә тигезләмәләр системасы ярдәмендә чишү” темасына ачык дәрес, “Математик марафон” кичәсе, “ 0 дән 10га кадәр” стенгазета яки буклетлар конкурсы; физика укытучысы Фаязов Ә.Ф. тарафыннан “Электр

тогы, электр тогы чыганаклары” темасына ачык дәрес, “Физика безнең тормышта” чарасы; информатика укытучысы Хөснетдинов А.А. тарафыннан “Табличные информационные модели” темасына ачык дәрес үткәрелде.

Уку елы дәвамында фән кабинетларында даими эш алып барылды. Һәр укытучы үз фәне буенча дидактик материаллар, күрсәтмә әсбаплар әзерләп, кабинет лабораториясен баету өстендә уңышлы эшләделәр. Математика кабинетында электрон лаборатория һәм кабинетның электрон паспорты булдырылды. Дәрес өчен барлык төр кулланма материалларның электрон тупланмасы булдырылды.

Киләсе уку елында уку сыйфатын тагын да үстерү, олимпиадаларда призлы урыннар алуга ирешү максаты куелды.

Методик берләшмә җитәкчесе: Р.Г.Гарифуллин

**Методик тема**: Укытуда яңа информацион технологияләр кулланып, укучыларның белем сыйфатын күтәрү.

**Максат**: Белем сыйфатын арттыру.

**2015-2016 уку елына бурычлар:**

1. Федераль дәүләт стандарты таләпләрен исәпкә алып, белем бирү процессында информацион-коммуникатив технологияләрне актив куллану; “Электрон Татарстан ” программасы белән эшләүне камилләштерү.

2.Белем сыйфаты динамикасын саклау максатыннан, укытучыларга төрле эш төрләре һәм яңа техноологияләрдән файдалануны, укучыларга нәтиҗәле белем бирүне мөһим бурыч итеп алу.

3.Укучыларның буш вакытларын нәтиҗәле файдалану өчен яшүсмерләрне иҗади, фәнни-эзләнү, проект эшчәнлегенә киңрәк тарту; укучыларның сәламәтлеген саклаучы технологияләр белән эшләүне дәвам итү; яшәү рәвешен пропагандалау; гражданлык активлыгын үстерү

## 2015-2016 нчы уку елына укыту-тәрбия планы

## I. Педагогик кадрлар белән эш, аларның квалификациясен күтәрү, аттестация.

| | Август-сентябрь | октябрь | ноябрь |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Педсовет утырышлары | 2014-2015 нче уку елының эш нәтиҗәләрен анализлау, алдагы уку елында мәктәпнең үсеш - юнәлешләрен билгеләү. | | Современный урок – основа эффективного и качественного образования |
| Кече педсовет | 1,5 сыйныфларда адаптация чоры, дәвамчанлык. | | |
| Методсовет утырышлары | 1.Яңа уку елына методик совет һәм методик берләшмәләрнең эш планын раслау.<br>2.1,5 класс укучыларының адаптация чорын тикшерү төркемен төзү.<br>3.Фән укытучыларының укыту программаларын карау һәм раслау.<br>5.Сәләтле балалар белән эшне оештыру. | 1. Фән олимпиадаларының мәктәп турын уздыру, район олимпиадаларына әзерлек<br>2. 1, 5 классларның белем алу эшчәнлеге мониторингы. ( кече педсоветка әзерлек) эшчәнлеген оештыру.<br>3. 3-4 класс укучыларыннан татар теле фәннәре буенча административ контроль эш, 9 кл. рус теле, математика фәннәреннән пробный алу өчен материаллар әзерләү.<br>4 Район эксперт комиссиясенә ачык дәрес бирүче укытучыларга методик ярдәм күрсәтү | 1. Аттестацияләнүче укытучыларның иҗат лабораторияләрен карау.<br>2. имтиханнарга әзерлек буенча информацион эшчәнлек.<br>3. Мәктәп фән олимпиадалары нәтиҗәсе, олимпиадаларның район турында катнашу.<br>4...Аттестация документлары әзерләү.<br>5. Район ГПД семинарына әзерлек. |
| Педагогларга аттестация үткәрү | 1. Авторлык программаларына экспертиза.<br>2.Аттестациягә керүчеләр исемлеге әзерләү, алар белән аттестация формасы һәм вакыты турында сөйләшү.<br>3.Укытучыларны аттестация буенча яңа аттестация үткәрү тәртибе белән таныштыру.(Приказ РФ №276, 07.04.14)<br>4 Аттестация буенча стендны җиһазлау.<br>5. Эш урынына аттестация үткәрүгә гаризалар кабул итү. | 1.Аттестация үтүчеләрнең гаризаларын кабул итү.<br>2.Аттестация үтүчеләргә эксперт комиссиясе эше. | 1.Аттестация үтүче педагогларның профессиональ эшчәнлегенә экспертиза |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Директор алды киңәшмәләре. | 1. Укучыларның җәйге ял нәтиҗәләре, мәктәпнең яңа уку елына әзерлеге.<br>2.Мәктәп китапханәсенең дәреслекләр белән тәэмин ителеше.<br>3. 1, 5 классларны комплектлау. Класс җитәкчеләре билгеләү.<br>4. 1 нче сентябрь – «Белем бәйрәме»нә әзерлекнең торышы.<br>5. Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру.<br>6. Белем алуга караш, тәртип мәсьәләләре, яшүсмерләр суицидын кисәтү, эти-әниләрнең кичке рейдларын оештыру буенча 9 нчы классларда эти-әниләр җыелышы уздыру. | 1. Укучыларның дәрескә йөрешен контрольдә тоту.<br>2. 1, 5 нче классларның адаптация чорына контроль.<br>3. Көзге каникулны үткәрү планы.<br>4. Ноябрь педсоветына әзерлек.<br>5. Тәрбиягә авыр бирелүче, тәрбияләнүче укучыларның укулары.<br>6. Эчке контроль нәтиҗәләре.<br>7.Классларда эти-әниләр җыелышлары. | 1. Мәктәптә санитария – гигиена таләпләренең үтәлеше.<br>2. Олимпиадаларның мәктәп турлары нәтиҗәләре, район турларында катнашу.<br>3. Укучыларның эчке тәртип кагыйдәләрен үтәүләре.<br>4.Эчке контроль нәтиҗәләре. |
